Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Колай авыл җирлеге

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Колай авыл җирлеге
Карповка торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
**КАРАР**

22 октябрь, 2023 ел № 3

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Колай авыл җирлегенең Карповка торак пунктында 2023 елның 22 октябрендәге гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә авыл җирлегендә яшәүчеләр белән очрашу беркетмәсе нигезендә:

- җыенны уздыру өчен билгеләнгән территориядә яшәүче һәм халык җыенында катнашырга хокуклы гражданнар саны 178 (йөз җитмеш сигез).
- халык җыены эшендә катнашкан гражданнар саны 112 (йөз унике).
- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**РИЗА**» өчен гомуми сан 104 (йөз дүрт).
- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**КАРШЫ**» өчен гомуми сан 8 (сигез).

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып түбәндәге карар кабул ителде:

1. «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25 статьясындагы 6 өлеше нигезендә түбәндәге сорау буенча гражданнар җыенының карары: «Сез, 2024 елда Карповка торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә, 1 төркем инвалидларын, хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларны, көндезге уку формасы студентларын һәм мәктәп укучыларын, 80 яшькә җиткән гражданнарны, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларын бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән (үзара салымнан) азат итеп, һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен тотылу белән килешәсезме?:

- су белән тәэмин итү системасын ремонтлау» **кабул ителгән дип санарга.**

2. Әлеге карарны «Вперёд» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) һәм Колай авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында да бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә).

Колай авыл җирлеге башлыгы Поповская Н.В. Поповская